…ЯЛТ ИТТЕР КҮҢЕЛЕҢНЕ СЫЗЫП АК НУР БЕЛӘН!

# Караш

1999 нчы елның 19 нчы маеннан чыга.
№ 1 2014. Сентябрь - октябрь
«НӘШРИЯТ ЭШЕ» түгәрәге

## 5 нче октябрь – Халыкара укытучылар көне.

Дөньядагы иң авыр эш нинди дисәгез – уйламыйча да әйтеп була, ул укытучы эше. Баланы 1 нче сыйныфтан 11 нче сыйныфка хәтле озатып барган, тормыш авырлыкларында да терәк булган укытучыларны ничек хөрмәт итмисең дә инде һәм ничек зурламыйсың. Бар тик аларның тырышлыгы белән бала зур үсеп җиткәч,зур-зур уңышларга ирешә, зур кеше була.

Укытучыларга үз эшләрендә хәйкәл куярлык аларга бит күпме бала күрергә туры килә һәрберсе аның үзенә күрә бер холыкка ия. Шул холыкларны бар тик укытучылар гына җиңә ала, берсеннән-берсе шук малай-кызларны тынычландыру, укуга кызыксыну тудыру, авыр темаларны җиңел итеп бирү аларның кулыннан гына килә. Чөнки бары тик аларда гына ниндидер тылсымлы бер көч, искиткеч сабырлык бар.

Безнең Лашман мәктәбе укытучылары – мәктәбебезнең горурлыклары, үз эшләренең осталары. Алар 200 гә якын балага һәр көнне яңадан-яңа белем бирәләр, олы тормышка аяк басарга өйрәтәләр. Хөрмәтле укытучыларыбыз! Сезне профессиональ бәйрәмегез белән ихластан котлыйм. Йөрәк җылыгызны биреп, күңелегездәге бар яхшылыкны балаларга бүләк итеп башкарган хезмәтегез өчен зур рәхмәтемне белдерәм.

***Гатина Инзилә, 6 нчы сыйныф укучысы***




*Сезнең өчен мәктәп изге йорт,*
*Үз итәсез һәрбер баласын.*
*Ачкыч табып сабый күңеленә*
*Белем орлыклары саласыз.*
*Күпме кыенлыклар кичергәнсез*
*Биргән чакта безгә тәрбия.*
*Хезмәтегез өчен һәр укучың*
*Хөрмәт белән бүген баш ия.*

БУ АЙДА... олимпиадаларның мәктәп туры тәмамланачак. Әлеге турда җиңүче укучыларыбызга мәктәп данын район турында яклау өчен күп көч куярга туры киләчәген аңлап, аларга уңышлар телибез. (Кемнәр ничек чыгыш ясавы турында мәгълүмат мәктәп сайтында урнаштырылган)

БУ АЙДА... шулай ук КФУ оештырган интернет олимпиадалар башланып китә. Бу олимпиадаларда катнашу өчен вакытында теркәлү узып, билгеле сәгатьләрдә биремнәрне эшләү кирәк.

БУ АЙДА... ниһаять “Көзге бал” булачак. Аны кызыклы һәм онытылмаслык итеп үткәрү үзебездән тора!!! Бәйрәмне актив һәм оешкан төстә уздырыйк.

БУ АЙДА... уку елының беренче чиреге тәмамлана. Традициягә кереп киткән “Икелеләрсез атна” нәтиҗәләренә караганда, күпләргә җиң сызганып тырышырга туры киләчәк. Сынатмыйк, җәмәгать!

БУ АЙДА... мәктәптә бассейн эшли башлады. Ниһаять, рәхәтләнеп йөзәчәкбез!!!

БУ АЙДА... ай бетүгә безне каникуллар көтә!

## Беренче укытучым.

Беренче укытучым! Кем генә бу исемне зур хөрмәт белән атамый икән. Һәркайсыбызның иң матур хәтирәләре, шатлыклыры, дулкынлануляры нәкъ менә беренче укытчылары белән бәйле. Мәктәп бусагасын атлап кергән вакыттан алып, бишенче сыйныфка кадәр безнең белән бергә укытучыбыз атлый. Минем беренче укытучым барлык матур сыйфатларны гына узенә туплаган. Аның сабырлыгын – ана сабырлыгына белән тиңләп була.

Әнә шундый абруйлы инде минем беренче укытучым. Ул тирән белемле башлангыч сыйныф укытучысы Динмөхәммәтова Кадрия апа Рәфкать кызы, аның бөтен гомере укыту, мәктәп, балалар, киләчәк өчен лаеклы алмаш үстерүгә багышлана.

Мин Кадрия апаның һәр дәресен яратып көтеп ала идем. Ул һәр теманы җентекләп аңлата иде. Авырракларын хәтта көне буе торып аңлатырга риза иде.

Безгә һәрвакыт ял итәргә кушса да үзенең ял иткәнен күргәнем юк. Ул безнең белән төрле сценарияләр һәм чаралар оештырырга да булыша иде. Кайчан ярдәм сорап килсәң дә, ул сине “вакытым юк” яисә “арыдым” дип кире борып җибәрми. Шуңа күрә аның яныннан кеше өзелми дә инде. Ул һәрвакыт игътибар белән тыңлар, аңлар һәм ярдәм итәр.

Аның өчен иң мөһиме мәктәп һәм без – укучылар. Кайвакыт анрга карап минем исем китә. Кайчан ял итәргә өлгерә икән соң ул? Һәрвакыт кочак-кочак дәфтәр тикшереп, күпме дәрескә план язасы да бар бит әле аның.

Мөгаен, ул төне буе эшлидер. Ә иртән елмаеп укучылары каршына кереп баса да:

- Исәнмесез, дәресне башлыйбыз... – дип яңа көнне башлап җибәрәдер.

*Жылы караш, назлы сүзләреннән*
*Тойдым синең йөрәк жылыңлы*
*Укытучым иң кадерле кешем*
*Бүләк итәм сезгә шушы сүзләремне.*

Нуретдинова Ләйлә
6 нчы сыйныф укучысы



## Минем яраткан сыйныф җитәкчем




Земфира Вәли улы Сөләйманова безнең 6 сыйныфның җитәкчесе. Тырыш, сабыр һәм бик акыллы безнең Земфира Вәлиевна.
Укытучы иң мөһим һәм кирәкле һөнәрләрнең берсе. Укытучылар булмаса, бөтен кешеләр надан булыр иде. Аларның һөнәрләре авыр, илебезгә күп файда китерә торган. Бөтен кешедә дәукытучы булырга сәләт юк. Бик түземле, башкалар белән аралаша белүче һәм белемле кешеләр генә укытучы була ала.

Земфира Вәлиевна безне 5 нче сыйныфка килгәч елмаеп каршы алды. Бу сыйныфта 20 бала. Ул безнең һәр беребезнең холкын-гадәтен белеп, күңелләребезгә үтеп керә белә, акыллы киңәшләре белән авыр чакларыбызда ярдәм кулы суза, кирәк чакта мактый, ә кайчак ачулана да белә. Ул безнең шатлыкларыбызга үзебездән дә артык сөенүче, ә уңышсызлыкларыбызга үзебездән дә артык көенүче.

Земфира Вәлиевна безнең мәктәптә инглиз теле укытучысы. Аның һөнәре бик авыр. Тик шулай да ул һәр бер дәрескә елмаеп килеп керә. Дәреснең авырлыгы да онытыла. Безнең хәлләребезне хәтта тәнәфестә дә белешә. Ул үзенең белемен һәрвакыт артырып тора. Чит илләргә барып та белемен артырып кайтты. Ул безгә һәрвакыт киәкле киңәшләр бирә. Төпле белем алып тормышта үз урыныгызны табыгыз диеп һәрдаим әйтеп тора. Ул һәрвакыт матур, килешле итеп киенә дә белә.

Еллар үткәч һәр кеше үзенең укытучысын хөрмәт белән искә ала. Мин дә укытучымны мәңге онытмам, аның биргән акыллы төпле киңәшләрен еллар буена искә тотармын.

Нуретдинова Наилә
6 нчы сыйныф укучысы

**“Караш” газетасының әлеге саны өчен җаваплы: Газимзянова Р. Ф.**
**Хәбәрләшү өчен телефон: 9270444015**